ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШАПШИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422708, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Шапши, ул. Ленина, 1

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШӘПШИ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422708, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Шәпши авылы, Ленин ур., 1

тел./факс 8(84365) 77-2-36, e-mail: Shap.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**08 июня 2021 ел** **№24**

**Биектау муниципаль районының Шәпши авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 21 апрелендәге 22 номерлы «Шәпши авыл җирлеге территориясендә чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яисә эшләнмәләрне яндыру урынын һәм ысулларын билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципаль районы Шәпши авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районының Шәпши авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 21 апрелендәге 22 номерлы «Шәпши авыл җирлеге территориясендә чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яисә эшләнмәләрне яндыру урынын һәм ысулларын билгеләү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Яндыруны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә башкарырга;

2) 5 пунктны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Шәпши авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А.Беляков